БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» 02 2022 ел № 110

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру барышында кулланыла торган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) формасын раслау турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 53 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру барышында кулланыла торган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) формасын кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2022 елның «18» 02
110 номерлы карарына
кушымта

**Форма**

**Муниципаль җир контроле кысаларында кулланыла торган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге)**

1. Әлеге тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда планлы тикшерүләр үткәргәндә кулланыла.

2. Планлы тикшерү предметы мәҗбүри таләпләрне үтәү белән чикләнә, аларны үтәү турында сораулар әлеге тикшерү кәгазенә (контроль сорауларга) кертелгән.

3. Планлы тикшерү аңа карата үткәрелә торган юридик затның исеме, шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), ИНН, ОГРН/ОГРНИП: ____________________________________________

4. Тикшерү кәгазен тутыру белән планлы тикшерү үткәрү урыны_____
____________________________________________________________

5.Планлы тикшерү үткәрү турында күрсәтмә: 20__ елның «___»______ ____ номерлы.

6. Планлы тикшерүне үткәрүче вазыйфаи затның (затларның) вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының атасы:__________________
_____________________________

7. Тикшерүнең хисап номеры һәм тикшерүләрнең бердәм реестрында тикшерүнең хисап номерын бирү датасы: ___________________________

8. Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыра торган сораулар исемлеге:

| N т/б | Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыра торган сораулар | Структур берәмлекләрен күрсәтеп, мәҗбүри таләпләр билгеләнгән норматив хокукый актлар реквизитлары | Сорауларга җаваплар | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Әйе | Юк | Кулланылмый | Искәрмә |
| 1 | Тикшерелүче юридик зат яки шәхси эшкуар тарафыннан җир кишәрлеге | Россия Федерациясе Җир | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | максатчан билгеләнеше һәм (яки) рөхсәт ителгән куллану төре нигезендә файдаланыламы? | кодексының 7 статьясындагы 2 пункты, 42 статьясы*(1) | | | | |
| 2 | Тикшерелүче юридик затның яки шәхси эшкуарның файдаланыла торган җир кишәрлегенә (файдаланыла торган җир кишәрлекләренә, җир кишәрлекләре өлешләренә) Россия Федерациясе законнарында каралган хокукы бармы? | Россия Федерациясе Җир кодексының 25 статьясындагы 1 пункты | | | | |
| 3 | Файдаланыла торган җир кишәрлегенә (файдаланыла торган җир кишәрлекләренә, җир кишәрлегенең бер өлешенә) хокуклар яки йөкләмә "Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында" 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә теркәлгәнме? | Россия Федерациясе Җир кодексының 26 статьясындагы 1 пункты, Россия Федерациясе Граждан кодексының 8.1 статьясы*(2) | | | | |
| 4 | Тикшерелүче юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан файдаланыла торган җир кишәрлегенең мәйданы хокук билгели торган документларда күрсәтелгән мәйданга туры киләме? | Россия Федерациясе Җир кодексының 25 статьясындагы 1 пункты, 26 статьясындагы 1 пункты | | | | |
| 5 | Юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан файдаланыла торган җир кишәрлеге чикләренең борылыш нокталарының нигезләмәсе Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында күрсәтелгән җир кишәрлеге чикләре нокталарының торышы турында белешмәләргә туры киләме? | Россия Федерациясе Җир кодексының 6 статьясындагы 3 пункты, 25 статьясындагы 1 пункты | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6 | Җир һәм җир кишәрлекләреннән файдалануга рөхсәт нигезендә, Дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлегеннән (җир кишәрлекләреннән) файдалану мондый җирләр яки җир кишәрлекләре чикләрендә туфракның уңдырышлы катламын бозуга яки юк итүгә китергән очракта, җирләр яки җир кишәрлекләре рөхсәт ителгән файдалану нигезендә фйдалануга яраклы хәлгә китерелгәнме? | Россия Федерациясе Җир кодексының 13 статьясындагы 5 пункты, 39.35 статьясындагы 1 пунктчасы | | | | |
| 7 | Сервитутның гамәлдә булуы туктатылган очракта, аңа карата сервитут билгеләнгән тикшерелүче юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан җир кишәрлеген рөхсәт ителгән файдалануга туры китереп файдалану өчен яраклы хәлгә китерү бурычы үтәлгәнме? | Россия Федерациясе Җир кодексының 13 статьясындагы 5 пункты, 39.25 статьясындагы 1 пунктчасы | | | | |
| 8 | Тикшерелүче юридик зат тарафыннан (дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы, дәүләт һәм муниципаль учреждение (бюджет, казна, автоном), казна предприятиесе, Россия Федерациясе Президентының үз вәкаләтләрен үтәүне туктаткан тарихи мирас үзәгеннән тыш) җир кишәрлегеннән (җир кишәрлекләреннән) даими (чикләнмәгән вакытлы) файдалану хокукын яңадан рәсмиләштерү яисә җир | "Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында" 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2 пункты*(3) | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | кишәрлеген (җир кишәрлекләрен) милеккә сатып алу хокукы башкарыламы? | | | | | |
| 9 | Җир кишәрлеген законнарда билгеләнгән вакытларда файдалану (үзләштерү) мәҗбүрилеге турында таләп үтәлгәнме? | Россия Федерациясе Җир кодексының 42 статьясы, Россия Федерациясе Граждан кодексының 284 статьясы, Россия Федерациясе Җир кодексының 45 статьясындагы 2 пункты, "Гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерциягә карамаган берләшмәләре турында" 1998 елның 15 апрелендәге 66-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 2 өлешенең 7 пункты*(4) | | | | |

«___» ______________ 20__ ел
(тикшерү кәгазен тутыру датасы күрсәтелә)

______________________ ___________ __________________________
(затның вазыйфасы) (имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)